# БАБАЛАРЫБЫЗ СОЛЫХНАМӘСЕ ҺӘМ НАМУС

*Халиуллина Р. И.*

# SOLYKHNAME OF ANCESTORS AND HONOR

*Khaliullina R. I.*

Россиядә элек-электән халык исәбен алу мәсьәләләренә зур игътибар юнәлтелгән. Бу аңлашыла да, чөнки илдә яшәүчеләрне барлау салым сәясәтенә бәйләнгән. XV–XVII гасырларда писцовый кенәгәләр төзелгән, 1897 елда Россия империясендә рәсми рәвештә беренче тапкыр гомуми халык санын алу уздырылган; даими рәвештә ревизия тасвирламалары (ревизские сказки), өстәвенә мөселман авылларында имамнарыбыз тарафыннан ел саен метрика кенәгәләре (1829–1918 елларда) алып барылган. Соңгыларында аерым бүлекләрдә кешеләрнең тууы, вафаты, никахлашуы һәм аерылышулары турында мәгълүматлар теркәлгән; кыскасы, мөселман руханилары хәзерге загслар вазифаларын да башкарганнар. Әлеге документлар хакында күпләребез хәбәрдар. Ә менә патриархаль гаиләләрдән башка чыгулар хакында солыхнамә дип аталган махсус килешүләр төзелгән. Алар әле киң гавамга бик үк мәгълүм түгелдер. Моңа аерым игътибар бирелгән, чөнки, ни дисәк тә, яңа хуҗалык – дәүләтнең салым өлкәсендә өстәмә керем бирәмлеге бит. Биредә без халкыбыз тарихын өйрәнүдәге шундый мөһим чыганакның бер үрнәген тәкъдим итәбез (гарәп графикасыннан безнең тарафтан 2016 елда күчерелде, стиле саклана). Ул 1912 елның 12 апрелендә Уфа губернасы Минзәлә өязе Әхмәт волостеның (Татарстанның хәзерге Зәй районы) Шыкмай авылында рәсмиләштерелгән. Солыхнамәнең төп нөсхәсе Ринат Минсалих улы Исрафиловның шәхси архивында саклана.

«1912 нче сәнәдә 12 нче апрельдә безки Хафизетдин һәм Шаһимәрдән Исрафиловлар аерылышмак булып, шаһитләр хозурында солыхнамә[1] яздырдык. Гакылымыз сәхих[2], тәнемез сәламәт вакытта хөсне[3] ризалыгымыз берлән һәм әнкәмезнең ризалыгы берлән бән, Хафизетдин Исрафил углы, тиешле хиссаны[4] алып, хөсне ризалыгым берлән чыкмак булдым. Шаһимәрдән Исрафил углы, әнкәләрен тәрбия кылып тормак булып, төп йортта калачак

[1] Солых килешүе, килешенү.

[2] Төпле, дөрес, сәламәт.

[3] Күркәм, яхшы.

[4] Өлеш, үзенә тиешле күләм, пай.

булды. Хафизетдин Исрафиловка нәсыйбына[5] тиешле нәрсәләр – бер келәт, аның соңында келәт берлән бер очтан 2 буй лапас 4 баганасы берлән, аннан соң тарантас арба, бер баш сарык, 3 пот бәрәңге, 2 сум 20 тиен акча, симинә үз душныкы үзенә, бер пот паек чыга. Сабанда үзе аласы булды шушы симинә паекны. Түләгән вакытта бергә түләргә вәгъдәләштек. Гыйниятулла Фәйзулла углына бирәсе 1 сум 50 тиен Хафизетдин Исрафилов зиммәсендә[6] калды, аннан соң өч сум урман өчен штраф Хафизетдин Исрафилов зиммәсендә калды. Өскә кия торган киемнәр, аяк киемнәре үзләренеке үзләренә булмак булды.

План пулный көенчә Шаһимәрдән Исрафиловка башка дәгъвам калмады дию, Хафизетдин Исрафил углы *X* тамга салдым.

Вә бән Шаһимәрдән Исрафил углы шушы язылмыш нәрсәләрне риза булып биреп һәм чыкмагына риза булып тамга *X* салдым.

Солыхнамә язган вакытта шаһитләр Хисмәтулла Бикбай углы тамга |-/[7] салдым һәм Гайнетдин Исмәгыйль углы тамга >< салдым.

Һәм шушы солыхнамә мәҗлесендә булдым олуг агалары бән Гайфетдин Исрафил углы тамга X салдым.

Шушы Исрафил Исрафиловның угылларының үтенүе буенча солыхнамә яздым бән Шәрифҗан Сәйфуллин.

Вә бән силскуй староста Гыйниятулла Фәйзулла углы кәҗүнни пичәтем бастым: Түгәрәк мөһер. X (Мөһердәге язу: печать старосты 4. участка Ахметевск волости)».

Бабаларыбыз нинди зирәк, акыллы булган! Әлеге солыхнамә үрнәге уртак йортта бер гаилә булып гомер сөргән туганнар гаиләләренең төп йорттан аерылып чыкканда үзара киңәш-табыш кылып, килешенеп эш йөртүе хакында сөйли. Бу исә алга таба тормыш иткәндә килеп чыгуы ихтимал бәхәсләрдән, низаглардан саклану чарасы да булып торган, шәхси җаваплылыкны көчәйтеп, татар гаиләсенең ныклыгын тәэмин итүдә уңай йогынты ясаган. Халык телендәге «Киңәшле эш – таркалмас» дигән зирәк гыйбарә дә юкка гына тумагандыр.

Солыхнамәдә телгә алынган затлар – Исрафил бабай нәселеннән. Әлеге нәсел вәкилләре гомер-гомергә ата-баба йоласын, гадәтләрен саклап, туганлыкның кадерен белеп, үзара ярдәмләшеп яшәгәннәр. Аларның яшәү рәвеше дә, гамәлләре дә халкыбыз һәм илебез тарихының аерылгысыз сәхифәләрен тәшкил итә. Хәзерге вакытта үз нәселенең тарихын барлау, шәҗәрәсен төзү белән шөгыльләнүче Ринат Минсалих улы әйтүенчә, аның борынгы бабалары балаларына Микаил, Исрафил кебек пәйгамбәрләр исемнәрен кушканнар. Җир белән бәйле вакыйгалар да, күмәкләштерү, кулаклыкка чыгару шаукымнары да, Бөек Ватан сугышы да әлеге нәсел вәкилләрен читләтеп узмый. Исрафил һәм Шаһимәрдән бабалары дәүләт файдасына тегермән һәм хәләл хезмәт куеп табылган башка мөлкәтләреннән

[5] Өлеш, пай.

[6] Бер эшне үз өстенә йөкләү, җаваплылыкны алу; йөкләмә.

[7] Бу тамга 4 санын уңнан сулга язган рәвештә.

ваз кичәләр. Документта телгә алынган Шаһимәрдәннең уллары Хөснимәрдән белән Габделәхәт Бөек Ватан сугышында катнашалар. Өлкән улы Хөснимәрдән 1945 елда Одер елгасын кичкәндәге батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеменә дә тәкъдим ителә. Аның шәхси сугышчан батырлыгы тасвирланган рәсми документта түбәндәге юллар бар (текст безнең тәрҗемәдә бирелә): «1945 елның 2 февралендә Одер елгасын кичкәндә иптәш Исрафилов төзәүче булган туп-туры төзәлештә (наводкада) торды. Туп уты белән дошманның 4 пулемёт ноктасы һәм 19 солдаты юк ителде, шуның нәтиҗәсендә майор Каверзнев батальоны (1208 нче укчы полк) уңышлы рәвештә Одерны кичте. Безнең частьларны Одер елгасының сул ярына бәреп чыгару максаты белән дошман һөҗүмгә күчте. Зур югалтулар бәрабәренә ул безнең оборонага үтеп керде. Туп пехота ышыклавыннан мәхрүм калды, Исрафилов яраланды, әмма сугыш кырыннан китмәде, төрле яклап туп өстенә ябырылган дошман солдатларын күзгә-күз атып кыруын дәвам итте. Әлеге бәрелештә иптәш Исрафилов тарафыннан дошманның үзйөрешле тубы, 4 пулемёт ноктасы, 150 солдаты һәм офицеры юк ителде һәм яраланды. Иптәш Исрафилов каһарманлыгы нәтиҗәсендә көн дәвамында немецларның 6 ярсулы һөҗүме кире кайтарылды һәм безнең гаскәрләрнең позицияләре торгызылды. Советлар Союзы Герое исеме бирелүгә тәкъдим итүгә лаек. 936 нчы артиллерия полкы командиры гвардия подполковнигы (имза) Савченко. 1945 ел 15 февраль».

Тик нигәдер каһарманга Герой исеме бирелми кала, аның батырлыгын бәяләү Кызыл Байрак ордены белән чикләнә. Хикмәт татарлыкта микән… Сугыштан соң Хөснимәрдән ага күмәк хуҗалыкны җитәкли.

Габделәхәт исә медсанчастьта хезмәт итә, яу кырыннан 500 дән артык яралыны чыгара, хезмәтен сугыш беткәч тә дәвам итеп, 1947 елга кадәр бандерачыларга каршы көрәштә катнаша, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Авыр сынауларга дучар булсалар да, әлеге нәсел вәкилләре намусларына тап төшермиләр. Ата-бабаларының алдан күрү, варисларының киләчәген кайгыртып яши белүләрен үрнәк итеп алып, үз тарихларын барлап, туганлык җепләрен саклап гомер кичерәләр. Ә солыхнамә исә аларга да, аның белән танышучыларга да тормыш рәвешен көйләүнең бер үрнәге, мөстәкыйльлеккә фатиха бирүче нәсыйхәтнамә булып тора.

**Сведения об авторе:** Халиуллина Рамзия Индусовна, ведущий методист Музейного комплекса города Казани, e-mail: xaliullina61@mail.ru.

**Аннотация:** Статья знакомит с особенностями доселе малоизвестного широкой общественности социально-юридического документа татарской сельской общины начала второго десятилетия XX в. Вводится в научный оборот один из образцов солыхнаме – соглашение о выделении в самостоятельное хозяйство, составленное 12 апреля 1912 г. в с. Шихмамаево Ахметевской волости Мензелинского уезда Уфимской губерии

(ныне Заинского района Республики Татарстан); освещаются ключевые моменты жизни некоторых продолжателей рода Исрафиловых, упомянутых в документе.

**Ключевые слова:** солыхнаме, свидетели, доля, обязательство, согласие, клеть, лапас, тарантас, штраф, претензия.

**Abstract:** The article introduces the peculiarities of the social and legal document of the Tatar rural community, hitherto little known to the general public, at the beginning of the second decade of the twentieth century. One of the samples of solykhname is introduced into scientific circulation – an agreement on the separation into an independent economy, drawn up on April 12, 1912 in the village. Shikhmamaevo Akhmetevskaya volost of Menzelinsky district of Ufa province (now Zainsky district of the Republic of Tatarstan); highlights the key moments in the life of some successors of the Israfilov family, mentioned in the document.

**Key words:** solykhname, witnesses, share, obligation, consent, crate, lapas, tarantass, fine, claim.